ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05. 03 2021 г. № 160

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Тышкы төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 1 октябрендәге 1870 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Тышкы төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 1 октябрендәге 1870 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның 3 пунктында «Л.Р. Юнысовка» сүзләрен «Р.М. Шәйдуллинга» сүзләренә алмаштырырга;

карарга кушымтада:

1.2 пунктта бишенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«- Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон белән»;

- «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата үткәрелә торган уртак планлы тикшерүләр турында» 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы РФ Хөкүмәте карары белән»;

түбәндәге эчтәлекле III.1 бүлекчә өстәргә:

«III.1. «Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыру үзенчәлекләре»

«3.1.1. АСИҮТ резидентларына карата алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә (алга таба – АСИҮТ) Федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге), региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контрольне Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары (алга таба – дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары) гамәлгә ашыралар.

«3.1.2. АСИҮТта дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру, АСИҮТ резидентларын тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү белән бәйле мөнәсәбәтләргә, «Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясында билгеләнгән тикшерүләр оештыру һәм уздыру үзенчәлекләрен исәпкә алып, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

3.1.3. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында планлы тикшерүләр, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы 3.1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль төрләреннән тыш, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле АСИҮТ резидентларына карата үткәрелә торган уртак планлы тикшерүләр турында» 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы РФ Хөкүмәте карары белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан уртак тикшерүләр рәвешендә үткәрелә.

Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнары вәкаләтле федераль орган белән килештерелергә тиеш. Вәкаләтле федераль орган һәм (яки) идарәче компания вәкиле планлы тикшерүләр үткәргәндә катнашырга хокуклы.

Планлы тикшерүне үткәрү срогы аны үткәрү датасыннан алып унбиш эш көненнән дә артмый. Кече эшкуарлык субъекты булган АСИҮТның бер резидентына карата план буенча планлы күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты елына кече предприятие өчен кырык сәгатьтән һәм микропредприятие өчен ун сәгатьтән артмаска тиеш. Тикшерү үткәрүче дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары вазыйфаи затларының дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак вакытлы махсус тикшерүләр һәм экспертизалар үткәрү зарурлыгына бәйле гадәттән тыш очракларда, тикшерү үткәрү вакыты озайтыла, ләкин кече предприятиеләргә карата утыз сәгатьтән, микропредприятиеләргә карата ун сәгатьтән дә артмый һәм АСИҮТның башка резидентларына карата унбиш эш көненнән дә артмый.

Югарыда күрсәтелгән абзацның нигезләмәләре шундый очракларда кулланылмый, әгәр «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның

1 статьясы 3.1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль төрләре өчен башка федераль законнар белән планлы тикшерүләр үткәрүнең башка вакытлары билгеләнгән булса.

Планлы тикшерү барышында АСИҮТ резиденты тарафыннан Россия Федерациясе законнарын бозу ачыклаганда, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль органнары вазыйфаи затлары АСИҮТ резидентына җитешсезлекләрне бетерү турында күрсәтмә бирә.

Җитешсезлекләрне бетерү турында күрсәтмәнең күчермәсе планлы тикшерү үткәрү нәтиҗәләре турында акт төзелгәннән соң өч көннән дә соңга калмыйча АСИҮТ резидентына яки аның вәкиленә раслама белән тапшырыла яисә АСИҮТ резиденты яисә аның вәкиле тарафыннан мондый күрсәтмәне алу датасы турында таныклаучы башка ысул белән тапшырыла. Әгәр күрсәтелгән ысуллар белән җитешсезлекләрне бетерү турында күрсәтмәне АСИҮТ резидентына яисә аның вәкиленә тапшыру мөмкин булмаса, ул почта аша заказлы хат белән җибәрелә һәм аны җибәргән көннән алып алты көн узгач алынган дип санала.

3.1.4. Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары, җитешсезлекләрне бетерү турында күрсәтмә бирелгән көннән соң ике ай вакыт узгач, АСИҮТ резидентына планнан тыш тикшерү үткәрелә. Җитешсезлекләрне бетерү өчен ике айдан артык вакыт кирәк булса, планнан тыш тикшерү, җитешсезлекләрне бетерү турында күрсәтмәдә билгеләнгән срокларда, әмма мондый күрсәтмә чыгарылган көннән алып алты айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

АСИҮТ резиденты планнан тыш тикшерү уздырганчыга кадәр җитешсезлекләрне бетерү турында күрсәтмәне үтәмәгән очракта, эшчәнлекне тормышка ашыру турындагы килешү гамәлдән чыгарылырга мөмкин һәм АСИҮТ резиденты статусы вәкаләтле федераль орган гаризасы нигезендә суд карары буенча туктатылырга мөмкин.

Планнан тыш тикшерүләр, вәкаләтле федераль орган белән килештереп, ул билгеләнгән тәртиптә үткәрелә. Планнан тыш тикшерү үткәрү вакыты биш эш көненнән дә артмаска тиеш.

Күрсәтелгән абзацның нигезләмәләре дәүләт серен саклауны тәэмин итүгә федераль дәүләт контролен гамәлгә ашырганда планнан тыш тикшерүләр үткәргәндә кулланылмый.

3.1.5. АСИҮТ резиденты дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан тикшерүләр үткәргәндә хокуклы:

1) контроль буенча чаралар үткәргәндә катнашырга, тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) аны бирү Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында каралган мәгълүматны алырга;

3) контроль буенча чаралар нәтиҗәләре белән танышырга һәм мондый нәтиҗәләр белән танышуны, алар белән килешү яки килешмәүне, шулай ук дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән танышуны актларда күрсәтергә;

4) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд тәртибендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль

органнары вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирергә.».»

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны матбугат басмасында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М. Шәйдуллинга йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов